ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**25 ноябрь 2024 ел** **№ 112**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе законы, 2018 нче елның 28 нче мартындагы 182 нче номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Красносельский авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2018 нче елның 4 нче маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Красносельский авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 24 сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 4 нче номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 55 нче номерлы, 2022 елның 25 ноябрендәге 60 нчы номерлы, 2023 елның 16 июнендәге 70 нче номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 97 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче пунктның 3 нче абзацында «13323» санын «13990» санына алмаштырырга;
- 2 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасарын акчалата бүләкләү

күләмнәре» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 10 нчы төркем |
| Авыл җирлеге Башлыгы урынбасары | 16995 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адрес буенча интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов